ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д. 3, с. Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк урамы, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**«24» декабрь 2021 ел** **№ 37**

**«Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Яңа Кырлай авыл җирлеге советының 28.10.2021 №33 карары, 05.11.2021 №1, 09.11.2021 №2, 09.11.2021 №3, 10.11.2021 №4, 10.11.2021 №5, 11.11.2021 №6, 12.11.2020 №7, 12.11.2021 №8 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Яңа Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1.« Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 3 нче йорт; Өчиле авылы, Тукай урамы, 73 нче йорт адреслары буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Яңа Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетының 18.12.2020 №31 «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башкарма
комитетының 24
декабрь 2021ел,№37
карарына
1 нче кушымта

**«Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү,җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә күрсәткән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә,2022 елның 12 февраленә кадәр муниципаль берәмлек территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а)көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсенә зыян килү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына (http://pravo.tatarstan.ru) сайтында басылып чыгу юлы беләнхәбәр ителә һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында ( http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмати стендларда, шулай ук кул куйдырып үзенә тапшыру яисә почта аша җибәрү юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар « Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, « Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башкарма
комитетының 24
декабрь 2021 ел, №37
карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________
«Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым
буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и.
а.и.________________________________________________________
Адресы:________________________________________________________________
_______________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр ________ сум күләмендә
____________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк ___________________________
Сч. № _______________________________________
Счетны алучы. № ______________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК _________________ОКАТО__________________
Түләү билгеләнеше
________________________________________________________________________
бер тапкыр түләнә торган түләү кертергә кирәк.

Җитәкче _________________ ________________________________________

М. у. (имза)( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы -- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.___________________________________________
Адресы: _______________________________________________
Алдым «___» _______________ 20__ ел
_____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*